**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең Тау Зары авылында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

13 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлегенең Тау Зары авылыда халык җыены турында карар бирә:

1. 2025 елда Балтач районы Карадуган авыл җирлеге Тау Зары авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

-урамнарны яктырту җайланмасы кую (Габдулла Тукай, Первомайская, Муса Җәлил, Главная, Поперечная урамнарна урам уты урнаштыру);

- һәйкәлләрне төзү (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары(тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган), ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (һәйкәлне ремонтлау).

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында ( pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе: Ш. В. Низамиев